МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

28.08.2023 Казан ш № 702

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының аерым боерыкларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә таныклыгын рәсмиләштерү һәм бирү эшен камилләштерү максатларында боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының аерым боерыкларына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

ОТДЕЛ ДЕЛО-ПРОИЗВОДСТВА

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2023 елның 28 августындагы 702 номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының аерым боерыкларына кертелә торган үзгәрешләр

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә таныклыгын рәсмиләштерү һәм бирү тәртибе турында» 2012 елның 4 сентябрендәге 697 номерлы боерыгында (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 16.09.2013 ел, №529, 17.05.2021 ел, №313, 23.05.2022 ел, №398 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән):

боерыкның аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Күпбалалы гаилә статусын билгеләү турында (Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә таныклыгын бирү, аның гамәлдә булу вакытын озайту һәм алмаштыру)»;

1 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Күпбалалы гаилә статусы билгеләү (Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә таныклыгын бирү, аның гамәлдә булу вакытын озайту һәм алмаштыру) тәртибе»;

әлеге боерык белән расланган Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә таныклыгын рәсмиләштерү һәм бирү тәртибендә:

аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Күпбалалы гаилә статусы билгеләү (Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә таныклыгын бирү, аның гамәлдә булу вакытын озайту һәм алмаштыру) тәртибе»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә таныклыгын рәсмиләштерү һәм бирүнең әлеге Тәртибе күпбалалы гаилә статусын билгеләү (Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә таныклыгын бирү, аның гамәлдә булу вакытын озайту һәм алмаштыру) кагыйдәләрен билгели.»;

2 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә таныклыгы, уллыкка алынганнарын да кертеп, фактта үзләре белән яши торган 18 яшькә кадәрге өч һәм аннан күбрәк баласы булган ата-ананың берсенә (алга таба – мөрәҗәгать итүче) Татарстан Республикасы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән очракта яки тору урыны буенча теркәлгән очракта (Россия Федерациясе территориясендә яшәү урыны буенча теркәлмәгән булса) бирелә.»;

4 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«4. Күпбалалы гаилә таныклыгын алу өчен мөрәҗәгать итүче Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының гаиләнең фактта яшәгән урыны буенча Социаль яклау идарәсенә

(бүлегенә) (алга таба – гаиләнең фактик яшәү урыны буенча Идарә (бүлек)) яки «Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесенә Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы раслаган форма буенча, гаилә составын һәм гаиләнең фактта яшәгән урынын күрсәтеп, күпбалалы гаилә таныклыгы бирү турында гариза һәм үзендә булган тормыш хәлләренә бәйле рәвештә түбәндәге документларны тапшыра:

баланың тууын теркәү турындагы таныклыкның чит дәүләтнең компетентлы органы тарафыннан бирелгән күчермәсе һәм аның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемәсе;

чит ил дәүләтенең компетентлы органы тарафыннан бирелгән гаилә коруны теркәү турында таныклык күчермәсе һәм аның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемәсе;

аерылышу турында чит дәүләтнең компетентлы органы тарафыннан бирелгән таныклык күчермәсе һәм аның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемәсе;

граждан хәле актларын теркәү органы яисә Россия Федерациясе консуллык учреждениесе тарафыннан бирелгән уллыкка алу турында таныклык күчермәсе;

белем алуына бәйле рәвештә ата-анасыннан читтә яши торган, 18 яшенә җитмәгән затлар өчен чит ил территориясендә бирелгән, Россия Федерациясеннән читтә белем алу турында документ күчермәсе һәм аның нотариаль таныкланган рус теленә тәрҗемәсе;

ир белән хатынның икенчесеннән түбәндәгеләрне раслый торган документ:

шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык һәм тарату өчен рөхсәт ителгән шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык (дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси мәгълүматларын эшкәртү кирәк булса һәм «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә мондый шәхси белешмәләрне эшкәртү күрсәтелгән затның ризалыгы белән башкарылган очракта, мөрәҗәгать итүче булып тормаган зат тарафыннан бирелә, күрсәтелгән зат хәбәрсез югалган дип танылган яисә эзләнүгә игълан ителгән һәм аның урнашу урыны вәкаләтле орган тарафыннан билгеләнмәгән очраклардан тыш);

шәхси мәгълүматларны органга яисә оешмага тапшырганда гариза бирүченең аның исеменнән эш кылуга вәкаләтле булуын. Ирнең яисә хатынның имзасы Идарә (бүлек) белгече тарафыннан, нотариаль рәвештә яки Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 185.1 статьясының 2 пунктында һәм Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 53 статьясының 2 өлешендә күрсәтелгән оешмалар һәм учреждениеләр тарафыннан таныклана;

мөрәҗәгать итүченең 3х4 см үлчәмендәге фотолары.

Гариза бирүче мөрәҗәгать иткәндә шәхесен таныклаучы документны күрсәтә.

Документларның күчермәләре, әгәр алар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, төп нөсхәләре белән бергә күрсәтелә һәм Идарә (бүлек) белгече тарафыннан таныклана. Документларның күчермәләре бер нөсхәдә тапшырыла.

Күпбалалы гаиләгә таныклык бирү турында гариза шулай ук, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасын кулланып, электрон рәвештә бирелергә мөмкин.

Гариза Идарәгә (бүлеккә) почта буенча җибәрелергә мөмкин. Бу очракта гаризага документларның Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган күчермәләре теркәлә.

Гариза Идарәгә (бүлеккә), фотоны таныклык алганда тапшырып, «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон һәм «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә имзаланган (таныкланган) электрон документлар формасында электрон чаралардан һәм (яки), «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре аша җибәрелергә мөмкин.

5 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«5. Идарә (бүлек) ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр нигезендә, шул исәптән электрон формада да, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасыннан файдаланып, вәкаләтле оешмалардан түбәндәге мәгълүматларны ала:

бала тууны дәүләт теркәвенә алу турында;

өйләнешүне (аерылышуны) дәүләт теркәвенә алу турында;

Россия Федерациясе чикләрендә яшәү (тору) урыны буенча теркәлү яисә теркәлмәү турында;

ата-ана хокукыннан мәхрүм ителү турында;

ата-ана хокукында чикләнү турында;

куркыныч янаганда баланы алу турында;

18 яшенә җитмәгән, белем алуына бәйле рәвештә ата-анасыннан аерым яши торган затлар өчен баланың белем алуы турында.

Әлеге Тәртипнең әлеге пунктында күрсәтелгән белешмәләре булган документларны мөрәҗәгать итүчеләр, аларның законлы вәкилләре яки ышанычлы затлар Идарәгә (бүлеккә) үз инициативасы белән тапшырырга хокуклы.»;

7 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«7. Күпбалалы гаилә таныклыгы бирүдән баш тарту нигезләре булып түбәндәгеләр тора:

әлеге Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегендәге документның тапшырылмавы;

дөрес булмаган белешмәләре булган документларның тапшырылуы;

мөрәҗәгать итүченең Татарстан Республикасы территориясендә яшәгән урыны буенча теркәлмәве яки торган урыны буенча (яшәгән урыны буенча теркәлмәгән очракта) теркәлмәве;

гаиләдә 18 яшькә кадәр өчтән азрак бала булуы;

ата-ана хокукыннан мәхрүм итү турында белешмәләр булуы (бердәнбер ата-ана (икесе) буенча);

баланың (балаларның) тулысынча дәүләт тәэминатында торуы турында белешмәләр булуы;

мөрәҗәгать итү вакытына билгеләнгән һәм гамәлдә булган күпбалалы гаилә статусы турында белешмәләр булуы;

ата-ана хокукында чикләнү турында белешмәләр булуы;

баланың (балаларның) гомеренә яки сәламәтлегенә турыдан-туры куркыныч янаганда баланың алынуы турында белешмәләр булуы.»

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә статусы билгеләү (Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә таныклыгын бирү, аның гамәлдә булу вакытын озайту һәм алмаштыру) буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 31 июлендәге 612 номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 02.09.2014 ел, №476, 07.06.2016 ел, №317, 24.07.2017 ел, №503, 07.05.2018 ел, №352, 18.09.2018 ел, №858, 12.11.2019 ел, №991, 06.04.2020 ел, №228, 13.07.2020 ел, №499, 09.10.2020 ел, №717, 18.06.2021 ел, №432, 01.10.2021 ел, №708, 11.04.2022 ел, №266, 24.06.2022 ел, №622 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә статусы билгеләү (Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә таныклыгын бирү, аның гамәлдә булу вакытын озайту һәм алмаштыру) буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

2 бүлектә:

2.2.2 пунктында «һәм (яки) КФҮнең ерактагы эш урыны» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.3.2 пунктның беренче абзацында «(озайту)» сүзләреннән соң «(озайтудан баш тарту) « сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле 2.3.3 һәм 2.3.4 пунктлары белән тулыландырырга:

«2.3.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып реестр язуы тормый.

2.3.4. Таныклык (таныклык дубликаты) бирү (вакытын арттыру) турында карар реквизитлары:

карар номеры һәм датасы;

карар кабул итүгә вәкаләтле органның исеме;

гаризаның номеры һәм датасы;

мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);

карар кабул итүгә вәкаләтле затның (алга таба – вәкаләтле зат) вазыйфасы;

вәкаләтле затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);

электрон имза турында белешмәләр.

Таныклык (таныклык дубликаты) бирүдән (вакытын озайтудан) баш тарту турында карар реквизитлары:

Таныклык (таныклык дубликаты) бирүдән (вакытын озайтудан) баш тарту турында карар реквизитлары;

карар кабул итүгә вәкаләтле органның исеме;

мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);

мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документлар;

таныклык (таныклык дубликаты) бирүдән (вакытын озайтудан) баш тарту турында карар кабул итү нигезләре;

вәкаләтле затның вазыйфасы;

вәкаләтле затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);

электрон имза турында белешмәләр.»;

2.4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4.1. Гариза һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан шәхсән тапшырылган очракта, дәүләт хезмәте Идарә (бүлек) тарафыннан гариза һәм әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән документлар теркәлгән көннән алып 10 календарь көн эчендә күрсәтелә.

Гариза һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар почта аша юллап җибәрелгән очракта, дәүләт хезмәте Идарә (бүлек) тарафыннан гариза һәм әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән документлар теркәлгән көннән алып 10 эш көне эчендә күрсәтелә.

Гариза һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы шәхси кабинет аша бирелгән очракта, дәүләт хезмәте Идарә (бүлек) тарафыннан гаризага эшләр номенклатурасы нигезендә номер һәм Бердәм порталда яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы шәхси кабинетта чагылдырыла торган «Документлар тикшерү» статусы бирелгән көннән башлап 10 эш көне эчендә күрсәтелә;

Гариза һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан КФҮ аша тапшырылган очракта, дәүләт хезмәте Идарә (бүлек) тарафыннан гариза һәм әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән документлар теркәлгән көннән алып 10 календарь көн эчендә күрсәтелә.»;

2.4.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4.3. Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә таныклыгы (таныклык дубликаты) бирү мөрәҗәгать итүче әзер таныклыкны (таныклык дубликатын) алу өчен мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Гариза һәм документлар (документларның күчермәләре) Идарәгә (бүлеккә) электрон документлар рәвешендә җибәрелгән очракта, таныклык (таныклык дубликаты) мөрәҗәгать итүче үзенең фотосы белән мөрәҗәгать иткән көннән соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча бирелә.»;

2.6.1 пунктының 3 пунктчасында:

унҗиденче абзацта «яки КФҮнең ерактагы эш урыны» сүзләрен төшереп калдырырга;

егерме икенче абзацта «, КФҮнең ерактагы эш урыны» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.6.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6.2. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алына торган документлар (белешмәләр):

баланың тууын дәүләт теркәвенә алу турында (Федераль салым хезмәтеннән);

өйләнешүне (аерылышуны) дәүләт теркәве турында (Федераль салым хезмәтеннән);

Россия Федерациясе чикләрендә яшәү урыны буенча теркәлү булу-булмавы турында (Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгыннан);

ата-ана хокукыннан мәхрүм итү турында (җирле үзидарә органнарыннан);

ата-ана хокукыннан чикләү турында (җирле үзидарә органнарыннан);

гомеренә яки сәламәтлегенә турыдан-туры куркыныч янаганда баланы алу турында (җирле үзидарә органнарыннан);

күпбалалы гаилә әгъзасының фамилиясен, исемен яки атасының исемен үзгәрткән

затлар өчен – фамилиясен, исемен яки атасының исемен үзгәртү турында (Федераль салым хезмәтеннән);

ата-ананың үлеме турында (Федераль салым хезмәтеннән);

нотариаль ышаныч турында (Федераль нотариаль палатадан);

гражданин паспортының чынлыгы турында (Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгыннан);

аталыкны билгеләү турында (Федераль салым хезмәтеннән);

18 яшенә җитмәгән, белем алуына бәйле рәвештә ата-анасыннан аерым яши торган затлар өчен баланың белем алуы турында (Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгыннан);

Мөрәҗәгать итүче югарыда аталган белешмәләрне раслый торган документларны үз инициативасы белән дә тапшырырга хокуклы.

Югарыда аталган белешмәләрне үз эченә алган әлеге документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан алынырга мөмкин, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон формада да, һәм әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында билгеләнгән документларны тапшыру өчен әлеге Регламентта каралган тәртиптә тапшырылырга мөмкин.

мөрәҗәгать итүченең югарыда күрсәтелгән документларны тапшырмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тормый.»;

2.13.1 пунктның җиденче абзацында «, КФҮ ерактагы эш урыны» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.13.4 пунктында «, КФҮ ерактагы эш урыны» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.13.5 пунктының беренче абзацында «, КФҮ ерактагы эш урыны» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.14.8 пунктны түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«Алдан язылу булмау мөрәҗәгать итүчене чират тәртибендә кабул итүгә комачауламый.»;

3 бүлектә:

3.2.2 пунктының беренче абзацында «, КФҮ ерактагы эш урыны» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.3.1 пунктта:

икенче абзацта «КФҮнең ерактагы эш урыны, « сүзләрен төшереп калдырырга;

унбишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Формалаштырылган гаризага формат-мантыйкый тикшерү Бердәм портал тарафыннан автомат рәвештә, гарызнамәдә электрон форманың һәр кырын мөрәҗәгать итүче тарафыннан тутыру барышында орган (оешма) билгели торган таләпләр нигезендә гамәлгә ашырыла. Бердәм порталда мөрәҗәгатьнең электрон формасындагы кырлар төгәлсезлекләр белән тутырылган булуы ачыкланган очракта, турыдан-туры мөрәҗәгатьнең электрон формасында мәгълүмат җиткерү юлы белән, мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында хәбәр ителә.»;

3.3.1.1 пунктының беренче абзацында «, КФҮ ерактагы эш урыны» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4. Ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга (оешмаларга) җибәрү

3.4.1. Идарәдә (бүлектә) теркәлгән гариза рәсми мөрәҗәгать җибәрү өчен нигез булып тора.

3.4.2. Идарә (бүлек) белгече электрон рәвештә түбәндәге белешмәләрне ала:

баланың тууын дәүләт теркәвенә алу турында (Федераль салым хезмәтеннән);

өйләнешүне (аерылышуны) дәүләт теркәве турында (Федераль салым хезмәтеннән);

3.4.3. Идарәдә (бүлектә) таныклык (таныклык дубликаты) бирү карарын кабул итүгә кирәкле мәгълүматлар булмаган очракта, Идарә (бүлек) белгече, шул исәптән электрон рәвештә дә, ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә түбәндәге белешмәләрне бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрә:

баланың тууын дәүләт теркәвенә алу турында (Федераль салым хезмәтенә);

өйләнешүне (аерылышуны) дәүләт теркәвенә алу турында (Федераль салым хезмәтенә);

Россия Федерациясе чикләрендә яшәү урыны буенча теркәлү булу-булмавы турында (Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгыннан);

ата-аналык хокукыннан мәхрүм итү турында (җирле үзидарә органнарына);

ата-аналар хокукларын чикләү турында (җирле үзидарә органнарына);

гомеренә яки сәламәтлегенә турыдан-туры куркыныч янаганда баланы алу турында (җирле үзидарә органнарына);

күпбалалы гаилә әгъзасының фамилиясен, исемен яки атасының исемен үзгәрткән кешеләр өчен үзгәртү турында (җирле үзидарә органнарына);

ата-ананың үлеме турында (җирле үзидарә органнарына);

нотариаль ышаныч турында (Федераль нотариаль палатага);

паспортның чынлыгы турында (Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгына);

аталыкны билгеләү турында (Федераль салым хезмәтенә);

18 яшенә җитмәгән, белем алуына бәйле рәвештә ата-анасыннан аерым яши торган затлар өчен баланың белем алуы турында (Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгына);

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза килгән көндә башкарыла. «Сорауга җавап законнарда билгеләнгән срокта керә.

Белешмәләрне куллануның максатлары булып мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документларның дөреслеген билгеләү, шулай ук законнарны һәм мөрәҗәгать итүченең хокукларын бозу очракларын булдырмый торган карарлар кабул итү тора.»;

3.6 пунктта:

өченче абзацта «КФҮнең ерактагы эш урыны» сүзләрен төшереп калдырырга;

дүртенче абзацта «КФҮнең ерактагы эш урыны» сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле 4.8 пункт өстәргә:

«4.8. Белешмә телефоннар, дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр Министрлыкның рәсми сайтында (http://mtsz.tatarstan.ru) урнаштырыла.»;

әлеге Регламентка кушымтаны (белешмәлекне) үз көчен югалткан дип танырга.